ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.09.2019 п.г.т.Алексеевское № 391

**Алексеевск муниципаль районы
башкармакомитетының
“Алексеевск муниципаль районында
белем бирү өлкәсендә вәкаләтләрне
чикләү турында”гы 06.04.2015 ел, 166 нчы
карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 26.07.2019 ел, 232-ФЗ санлы Федераль закон таләпләренә, мәгариф һәм фән өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы башкару хакимияте федераль органнары структурасын үзгәртү уңаеннан Россия Федерациясе аерым закон ак тларына туры китерү максатында

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының “Алексеевск муниципаль районында белем бирү өлкәсендә вәкаләтләрне чикләү турында”гы 06.04.2015 ел, 166 нчы карарына үзгәрешләр кертергә һәм кушымтаның 3 нче пунктындагы 3.17 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.17. Наркотик һәм психотроп матдәләрнең законсыз кулланылуын иртә ачыклау максатында укучыларга социаль-психологик тест оештыру. Гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыру тәртибе гомуми белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру, норматив-хокукый җайга салу вазыйфаларынгамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.Югары белем бирү оешмаларында укучыларга социаль-психологик тест үткәрүне оештыру тәртибе югары белем бирү өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм тормышка ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

2. "Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге" МКУ башлыгына локаль-норматив актларны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өчен аны Алексеевск муниципаль районының белем

биру оешмалары җитәкчеләренә җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.П.Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**